# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **10.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Керәш- Шуран авыл җирлеге составына керүче
Таш-Елга торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Керәш- Шуран авыл җирлегенә керүче Таш-Елгаы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Таш-Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан тыш, көндезге формада укучы студентларга 500 (биш йөз) сум күләмендә, үзара салым кертергә.
2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Таш-Елга авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Таш-Елга авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итүгә, Таш-Елга авылы җирлегендә рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыруга;
- Таш-Елга авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- Таш-Елга авылы җирлеген төзекләндерүне оештыруга;
- Таш-Елга авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүгә, Таш-Елга авылы суларын чыгаруны оештыруга;
- Таш-Елга авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Таш-Елга авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда , Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Керәш -Шуран авылы, Үзәк урамы, 6А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Керәш- Шуран авыл җирлеге башлыгы Р.Г.Сафиуллин